# ЭШ ДӘФТӘРЕ

**Балалар бакчасының зурлар төркеменә йөрүче балаларда коррупциягә каршы фикерләү формалаштыру**





МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ ПЕДАГОГЛАРЫ
ҺӘМ АТА-АНАЛАР ӨЧЕН

ББК 74.100.5
Р12

**Проектның җитәкчесе:** Хәмитов Р.Г., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты ректоры, педагогика фәннәре кандидаты, доцент

**Автор-төзүчеләр:** Руднева Я.Б., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының фәнни һәм инновацион эшчәнлек буенча проректоры, тарих фәннәре кандидаты

Манюрова Г.Х., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының мәктәпкәчә яшьтәгеләргә белем бирү лабораториясе мөдире, педагогика фәннәре кандидаты

Зарипова З.М., педагогика фәннәре кандидаты, Икътисад, идарә һәм хокук институты доценты

Кидрячева Р.Г., Яр Чаллы шәһәренең «Баланың сәләтен үстерү үзәге – «Фея» 83 нче балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе

Исаева Р.С., Яр Чаллы шәһәренең «Баланың сәләтен үстерү үзәге – «Балачак планетасы» 98 нче балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе

**Татар теленә тәрҗемә:** Шәмсетдинова Р.Р., Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент

**Рецензентлар:** Измайлова Э.А., Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәктәпкәчә яшьтәгеләргә белем бирү бүлеге җитәкчесе

Гаффарова С.М., Казан педагогия көллияте директоры урынбасары

Эш дәфтәре мәктәпкәчә белем бирү белгечләре, ата-аналар өчен балалар бакчасының зурлар төркеменә йөрүче балаларда әхлакый-этик тәҗрибә формалаштыру үзенчәлекләрен исәпкә алып эш оештыру өчен эшләнде.

© ГАОУ ДПО ИРО РТ, 2016

## Беренче номерлы «Серенә төшен» биремен башкару этаплары

1. Балалар белән бергәләп «Шалкан», «Кызыл калфак», «Доктор Айболит», «Бүре һәм җиде кәҗә бәтие» әкиятләрен укыгыз.

2. Балаларга эш дәфтәрендәге әкият персонажлары сурәтләнгән рәсемнәрне карарга тәкъдим итегез.

3. Балалар белән әкият персонажлары сурәтләнгән рәсемнәр буенча фикер алышыгыз: үзләре укыган әкиятләрдәге кайсы персонажларны таныганнар һәм атый алалар, алар фикеренчә, әкият персонажларының кайсылары яхшы гамәлләр, кайсылары начар гамәлләр кылалар.

4. Балаларга, эш дәфтәрендәге биремнәрне башкарганда, персонажлары яхшы гамәлләр кылган әкиятләрдән соң бирелгән шакмакларны кызыл төстәге карандаш, персонажлары начар гамәлләр кылган әкиятләрдән соң бирелгән шакмакларны зәңгәр төстәге карандаш белән буярга тәкъдим итегез.

5. Балалар белән әңгәмә оештырыгыз.

## Икенче номерлы «Докторга нәрсә кирәк?» биремен башкару этаплары

1. Авторның балаларны дәвалау өчен банан сораган доктор турындагы әкиятен бергәләп укыгыз.

Бик нык дулкынлаган, борчылган маймыл доктор янына йөгереп килә.

Маймыл: Бәла! Бәла! Тизрәк! Тизрәк! Коткарыгыз! Коткарыгыз!

Доктор: Маймыл, тынычлан зинһар. Барысын да тәртип белән,ашыкмыйча гына сөйләп бир әле.

Маймыл: Бәла! Африкадагы барлык балалар авырыйлар! Аларның эчләре авырта!

Доктор: Бу эпидемия! Маймыл, әйдә, бергәләшеп уйлашыйк әле, аларга ничек итеп ярдәм итәргә мөмкин икән соң?

Маймыл: Доктор, уйлап торырлык вакытыбыз юк бит, әйдәгез, тизрәк Африкага очыйк.

Доктор: Маймыл, мин бара алмыйм. Беренчедән, минем вакытым юк. Икенчедән, дарулар юк. Өченчедән, акча юк.

Маймыл: Коточкыч хәл бит бу, коточкыч. Безнең балаларыбыз нишләр инде хәзер? Доктор, берәр нәрсә уйлап табыйк, зинһар өчен?

Доктор: Яхшы! Беләсезме, сез миңа тиз арада Африкадан самолет белән банан җибәрсәгез, мин сезнең балаларыгызны дәвалармын.

Маймыл: Доктор, үтенеп сорыйм, хәлебезгә керегез! Без авырган балаларыбыз белән бер самолет бананны берничек тә җыеп бетерә алмаячакбыз бит?

Доктор: Мин бер кешенең дә хәленә керергә җыенмыйм. Банан җибәрмәсәгез, балаларыгызны дәваламыйм!

2. Балалар белән әңгәмә оештырыгыз: доктор дөрес эшлиме?

3. Биремне эш дәфтәрендә башкарыгыз. Бирем: докторның сурәтен сызыклар ярдәмендә балаларны дәвалау өчен кирәк булган предметлар белән тоташтырырга.

4. Биремнәрне башкарганнан соң, балалар белән әңгәмә оештырыгыз.

## Өченче номерлы «Ни чәчсәң, шуны урырсың» биремен башкару этаплары

1. Балалар белән бергәләп «Аю белән бабай» («Тамырлар һәм сабаклар» – «Вершки и корешки») һәм «Алтын бөртекләр» («Золотые зёрнышки») әкиятләрен укыгыз.

2. Таныш булмаган сүзләрнең мәгънәләрен аңлатып, әкиятләрнең эчтәлекләре буенча әңгәмә оештырыгыз.

3. Балаларга эш дәфтәрләрендә сурәтләнгән әкият геройларын игътибар белән карарга тәкъдим итегез.

4. Балаларга рәсемнәр арасыннан, үзләре уңай герой сурәтләнгән дип санаганын сайлап алып, эш дәфтәрләрендә билгеләргә тәкъдим итегез.

5. Биремнәрне башкарганнан соң, балалар белән әңгәмә оештырыгыз.

### Дүртенче номерлы «Буйыйбыз» биремен башкару этаплары

1. Балалар белән бергәләп «Өч дуңгыз баласы» әкиятен укыгыз.

2. Әкият персонажларының кылган гамәлләрен бәяләүгә корылган әкият турында фикер алышуны оештырыгыз. Геройларның кайсы яхшы, ә кайсысы начар гамәл кылган?

3. Балаларга эш дәфтәрендә яхшы гамәл кылган геройларны ал төс белән буярга тәкъдим итегез.

4. Балаларга эш дәфтәрендә начар гамәл кылган геройларны соры төс белән буярга тәкъдим итегез.

5. Биремнәрне башкарганнан соң, балалар белән әңгәмә оештырыгыз.

### Бишенче номерлы «Намуслы малай» биремен башкару этаплары

1. Балалар белән бергәләп «Намуслы малай» («Честный мальчик») исемле корея халык әкиятен укыгыз.

2. Балалар белән әкиятнең эчтәлеге буенча фикер алышу оештырыгыз:

– Әгәр дә малай картка алтын яки көмеш балтаны үзенеке дип әйтсә, нәрсә булыр иде икән?

– Күлдән чыккан карт кем булган? Ул ни өчен малайны намуслылык ягыннан тикшереп карарга булды икән?

– Сезнең тормышыгызда, авырлыкка очраганда, намуслылыкның ярдәмгә килү очрагы булдымы?

– Намуслы булырга теләүчегә сез нинди тылсымлы киңәш бирер идегез?

3. Балалар биремнәрне эш дәфтәрендә эшлиләр, аларның бурычлары – малайның рәсемен, сызык аша, үзләре дөрес дип санаган җавап белән тоташтыру.

4. Биремнәрне башкарганнан соң, балалар белән әңгәмә оештырыгыз.

### Алтынчы номерлы «Дөрес җавап тап» биремен башкару этаплары

1. Биремне башкару алдыннан балалар белән әңгәмә үткәрегез һәм бирелгән ситуациянең мәгънәсен аңлатыгыз: балага, йокларга ятыр алдыннан, көн дәвамында уйнаган уенчыкларын җыеп куярга кирәк.

Бу биремне башкару өчен, балага түбәндәге ысулларның берсен сайлап алырга тәкъдим ителә:

А) Уенчыкларны җыеп кую өчен, энеңә (яки сеңлеңә) конфет бирү;

Б) «Мин теләмим!» дип баш тарту һәм йокларга яту;

В) Уенчыкларны мөстәкыйль җыеп кую.

2. Балаларга эш дәфтәрендә үзләре дөрес гамәл дип санаган очракны буярга тәкъдим итегез.

3. Биремнәрне башкарганнан соң, балалар белән әңгәмә оештырыгыз.

### Җиденче номерлы «Рәсемнәрдәге тарих» биремен башкару этаплары

1. Балаларга эш дәфтәрендәге рәсемнәрне игътибар белән карарга һәм анда сурәтләнгән затларның үз-үзләрен тотышларына бәя бирергә тәкъдим итегез.

2. Фикер алышу оештырыгыз.

3. Балаларга рәсемнәрне үзләре дөрес дип тапкан эзлеклелектә тоташтырырга тәкъдим итегез.

4. Әңгәмә оештырыгыз.

## Сигезенче номерлы «Нәрсә начар, нәрсә яхшы» биремен башкару этаплары

1. Балаларга эш дәфтәрләрендә сурәтләнгән персонажларның үз-үзләрен тотышларына бәя бирергә тәкъдим итегез.

2. Балаларга үзләре яхшы санаган гамәлләр сурәтләнгән рәсемне сайлап алырга тәкъдим итегез. Бу рәсемне елмайган смайлик белән тоташтырырга кушыгыз.

3. Балаларга үзләре начар санаган гамәлләр сурәтләнгән рәсемне сайлап алырга тәкъдим итегез. Бу рәсемне елаган смайлик белән тоташтырырга кушыгыз.

4. Биремнәрне башкарганнан соң, балалар белән әңгәмә оештырыгыз.

## Тугызынчы номерлы «Яхшы гамәлне тап» биремен башкару этаплары

1. Балаларга эш дәфтәрендәге рәсемнәрне игътибар белән карарга һәм анда сурәтләнгән затларның үз-үзләрен тотышларына бәя бирергә тәкъдим итегез.

2. Балаларга, алар фикеренчә, яхшы гамәлләр сурәтләнгән рәсемне сайлап алырга тәкъдим итегез. Бу рәсемне түгәрәк эченә алырга кушыгыз.

3. Биремнәрне башкарганнан соң, балалар белән әңгәмә оештырыгыз.

## Унынчы номерлы «Җавабын тап, аңлат һәм буя» биремен башкару этаплары

1. Балаларга түбәндәге табышмакларның җавабын табарга тәкъдим итегез:

1. Зурдыр, сорыдыр, усалдыр,
Куяннарга тиядер. (Бүре)

2. Алда – борын,
Артта – койрык.
Уртада кыллы арка.
Ниф-Ниф түгел, Нуф-Нуф түгел,
Хезмәт сөючән ...... (Наф-Наф)

3. Патша түгел, үзе таҗлы
Төлке түгел – койрыклы.
Сәгать түгел – уята
Тукмар түгел, ә аның дусты.... (Чукмар)

4. Аягым юк, үзем йөрим
Авызым юк, үзем исә,
Кемгә кайчан йокларга,
Кемгә кайчан торырга
Икәнен белеп әйтәм.
Тыңлаучан балаларны яратам,
Сүзендә тормаганнарны яратмыйм...
(сәгать)

2. Балаларга эш дәфтәрендә үзләре дөрес дип санаган рәсемнәрне буярга тәкъдим итегез.

3. Биремнәрне башкарганнан соң, балалар белән әңгәмә оештырыгыз.

1нче бирем. «Серенә төшен»









2нче бирем. «Докторга нәрсә кирәк?»




Знче бирем. «Ни чәчсәң, шуны урырсың»





4нче бирем. «Буйыйбыз»



5нче бирем. «Намуслы малай»




**6нчы бирем. «Дөрес җавап тап»**



7нче бирем. «Рәсемнәрдәге тарих»









8нче бирем. «Нәрсә начар, нәрсә яхшы»












9нчы бирем. «Яхшы гамәлне тап»












10нчы бирем. «Җавабын тап, аңлат һәм буя»







# ЭШ ДӘФТӘРЕ

**Балалар бакчасының зурлар төркеменә йөрүче балаларда коррупциягә каршы фикерләү формалаштыру**

Мәктәпкәчә белем бирү педагоглары һәм ата-аналар өчен

Корректура, компьютерная верстка, техническое редактирование
Гиниятуллина Р. С., Некратова А. В.

Художественное оформление
Мингазова М. Ю., Федорова О. В.

Форм. бум. 60х84 $^{1}/_{8}$. Гарнитура Pragmatica.
Усл. печ. л. 2.

Оригинал-макет подготовлен в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
www.irort.ru, irort2011@gmail.com